

Ләмберә районы Чирмеш авылындагы «Битараф булмаганнар» ятмә vрvчеләр торкемендә алты кеше. Болар - Клара Ибраһим кызы Сюбаева, Фатиха Үмәр кызы Солдатова, Равилә Үмәр кызы Судьенкова, Роза Әмин кызы Маринова, Нәим Жәфәр улы Кряков һәм аларнын житәкчесе Винера Халит кызы Аббясова.      Кон саен иртән алар Чирмеш мәктәбе холлына эшкә килгән кебек киләләр. Хәер, кvбесе кvптән пенсиядә. Башкача булдыра алмыйлар; хәзер СВО зонасында булган балалар очен кvнел әрни, диләр. Һәм vз момкинлекләре булганчы ярдәм итәләр: маскировка ятьмәләре vрәләр, посылкалар жыялар һәм аларнын һәрбересен ойләренә котәләр. Ярдәм итvчеләр очен сугышчылар барысы да vзләренеке, туганнары. Әлеге Ватанга ярдәм итvчеләрнен житәкчесе Аббясова Винера Халит кызыннан эш турында сорагач болай ди:



- Чирмеш авылы мәктәбе холлында, хәтта шимбә конне дә, кешеләр кvп иттереп жыела. Олкәннәр маскировка челтәрләре vрәсәләр, укучылар СВО зонасындагы сугышчыларга хатлар язалар. Әлеге хатын-кызлар гаиләләренә дә вакыт бvлеп куярга, солдатларга да ярдәм итәргә олгерәләр.

Ә эш шулай башлана: Чермиш авылынын башта санап киткән биш пенсионеры 2024 елнын сентябрендә, ойдә генә утырырга ярамый, дип карар кылалар. Эш башлана да, дәвам да итә, нәтижәләре дә шатландыра. СВО зонасындагы хәрби техниканы һәм блиндажларны яшерv очен кулланыла торган 60тан артык маскировка челтәре vреп жибәргәннәр инде. Безнен сугышчылар мондый маскировка чараларына мохтаж. Әлеге Чирмешлеләр челтәр генә vреп калмыйлар, гуманитар ярдәм дә жыеп СВОчыларга жибәрәләр. Чынлыкта маскировка челтәрләрен vрv жинел тvгел, бу физик яктан авыр эш. Хатын-кызлар аяк остендә берничә сәгать басып торалар, аскы рәтләрне vргәндә генә утыралар. Ләкин сойләшvләр, авыл яналыклары турында фикер алышулар һәм мәзәкләр белән эшләгәндә вакыт тиз уза. Нәим Жәфәр улы Кряков, Клара Ибраһим кызы Сюбаева, Фатиха Үмәр кызы Солдатова, Равилә Үмәр кызы Судьенкова, Роза Әмин кызы Маринова, Винера Халит кызы Аббясова кvптән инде туганлашканнар; кайгы-хәсрәттә дә, шатлыкта да бер-берсенә ярдәмләшеп яшиләр.

**Наилә НАСЫРОВА**